СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

27.03.2017 № 13/8

На № ________ от ________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 һәм 42 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 22 февралендәге 7 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

а) 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 абзац өстәргә:

«Отличие белән белгеч яисә магистр дипломы булган затлар өчен диплом бирелгән көннән алып өч ел эчендә муниципаль хезмәт стажына яисә муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын биләү өчен белгечлек буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнә - кимендә ярты ел муниципаль хезмәт стажы яисә бер ел белгечлек буенча эш стажы.»

2. Әлеге карарны рәсми мәгълүмат порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев